РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 36

2020 елның 29 апреле

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2012 елның 24 февралендәге 18 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм туктату һәм аны билгеләгән өчен тигез күләмле түләү тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2012 елның 24 февралендәге 18 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм туктату һәм аны билгеләгән өчен тигез күләмле түләү тәртибе турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 нче кушымтада:

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 9 пунктча өстәргә:

«9) РФ Җир кодексының 39.37 статьясында каралган максатларда җир кишәрлегеннән файдалану»;

17 пунктның 2 абзацында « ачык сервитутны билгеләүгә охшаш тәртиптә, яисә суд карары нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18) Иҗтимагый фикер алышулар Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә җәмәгать фикер алышуларын һәм гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» 2006 елның 13 октябрендәге 48 номерлы карары белән каралган тәртиптә үткәрелә.

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе ачык сервитутлар билгеләү буенча иҗтимагый тыңлауларның бәяләмәләрен һәм беркетмәләрен саклау өчен җаваплы орган булып тора.»;

4,5 пунктларны, 11 пунктның 2-4 абзацларын, 19-22 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны төзелеш, җир төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

А.Р.Метшин